ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.08.2016 с. Введенская Слобода №62

### Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

1.1. Күчемсез милек объекты адресын бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Җир кишәрлегенә белешмә бирү, йорт биләмәсенә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты
(5 нче кушымта).

1.6. Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.8. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.9. Васыятьләр таныклыгы буенча һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 13 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектын бирү, үзгәртү һәм аның адресын юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 09.12.2015 ел № 127 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозов